ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ
Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының
«Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Варклед-Бодья торак
пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**24.11.2022** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Варклед-Бодья торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2022 елның 24 ноябрендә 10:00 сәг уздырылган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2023 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Варклед-Бодья торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 400 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Варклед- Бодья торак пункты урамнарын кардан чистарту.
2. Варклед-Бодья торак пунктының су челтәрләренә хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау, бер фазалы насос һәм башка материаллар комплекты сатып алу.
3. Янгын помпасы сатып алу һәм Варклед-Бодья торак пунктының янгын сүндерү машинасын йөртүчегә хезмәт килешүе буенча түләү.
4. Урам утларын, электр товарларын сатып алу, урнаштыру һәм алыштыру.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 252 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 141 кеше, бу 55,9 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 141 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Варклед-Бодья торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. 2023 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Варклед-Бодья торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертергә.

3. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1. Варклед- Бодья торак пункты урамнарын кардан чистарту.
2. Варклед-Бодья торак пунктының су челтәрләренә хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау, бер фазалы насос һәм башка материаллар комплекты сатып алу.
3. Янгын помпасы сатып алу һәм Варклед-Бодья торак пунктының янгын сүндерү машинасын йөртүчегә хезмәт килешүе буенча түләү.
4. Урам утларын, электр товарларын сатып алу, урнаштыру һәм алыштыру.

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Авыл җирлеге башлыгы Р.А.НУРМӨХӘММӘТОВ